КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 сентябрь г.Казань № 799

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Лаеш муниципаль районы территориясендә, «Көньяк паркы» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:119), «Ел вакыты» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:120), «Юбилей станциясе» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:118) керүне һәм алардан чыгуны оештырып, «Казан – аэропорт» аэроэкспрессының тимер юллары һәм «Казан – Боровое Матюшино» автомобиль юлы кисешкән урында транспорт чишелеше – төбәк әһәмиятендәге объектны урнаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII$^{1}$ бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Лаеш муниципаль районы территориясендә, «Көньяк паркы» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:119), «Ел вакыты» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:120), «Юбилей станциясе» торак комплексына (кадастр саны 16:24:150302:118) керүне һәм алардан чыгуны оештырып, «Казан – аэропорт» аэроэкспрессының тимер юллары һәм «Казан – Боровое Матюшино» автомобиль юлы кисешкән урында транспорт чишелеше – төбәк әһәмиятендәге объектны

урнаштыру максатларында, «Южная поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрекләре милекчесе) милкендәге 9 682 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) бу карарга теркәлә торган исемлек нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыруны;

бу карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару;

бу карарның күчермәләрен Татарстанның юл-транспорт идарәсенә, алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрүне;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имзаланган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта бирелмәгән очракта, тиешле дәгъваларны судка бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 сентябрь, 779 нчы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен
алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Кадастр саны | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 16:24:150302:1149 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 515 | «Южная поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 2. | 16:24:150302:1154 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 2 016 | «Южная поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 3. | 16:24:150302:1150 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 6 924 | «Южная поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 4. | 16:24:150302:1146 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 227 | «Южная поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| Барлыгы | | | 9 682 | |